| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 12.12.2016 г. Казань № 4-3/г

2017 елга Татарстан Республикасын газлаштыру программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәтләре өчен тарифларга махсус өстәмә бәяләр күләмен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ санлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2001 елның 3 маендагы «Газлаштыру программасын финанслау өчен газ бүлүче оешмалар тарафыннан газны транспортировкалау тарифларына махсус өстәмә бәяләрне билгеләү тәртибе турында» 335 санлы карарына, тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2011 елның 21 июнендәге «Газлаштыру программасын финанслау өчен газ бүлүче оешмалар тарафыннан газны транспортировкалау тарифларына махсус өстәмә бәяләр күләмен билгеләү Методикасын раслау турында» 154-э/4 санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 декабренә кадәр, барлык кулланучылар төркемнәре өчен (халыктан гайре) Татарстан Республикасын газлаштыру программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлау хезмәтләре өчен тарифларга махсус өстәмә бәяләр күләмен 2017 елга, билгеле бер календарь чорларына бүлеп, әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 12.12.2016 № 4-3/г
карарына кушымта

2017 елга, билгеле бер календарь чорларына бүлеп, Татарстан Республикасын газлаштыру программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлау хезмәтләре өчен тарифларга махсус өстәмә бәяләр күләмнәре

| Татарстан Республикасының газ бүлүче оешмасы атамасы | Ел | 1000 куб.метр өчен махсус өстәмә бәя күләме ( НДСтан тыш) |
|---|---|---|
| «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 42,51 |
| | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 44,17 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тарифлар буенча карарлар
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге